булып торалар. Әгәр шәригать буенча ир белән хатынның бер-берсенә карата булган вазыйфалары хакында сөйләшсәк, ул чакта бик күп язарга туры киләчәк. Бигрәк тә безнең вакытта бу йөкләмәләрнең бөтенесен үтәү бик катлаулы. Ә иярү мөмкин булган, авыр булмаган һәм хәтта мәҗбүри булган нәрсә - ул бер-береңне гафу итү, тәүбә итү, башкача бер генә кеше дә хатын-кызга ире эчкән өчен аннан китәргә киңәш итмәс. Әмма әгәр дә аңа аның белән яшәү бик авыр булса һәм ул моңа түзә алмаса, ул чакта китсен, моның белән берәү дә бәхәсләшми бит.

**Сәед ӘЛ-ЧИРКАВИ.**
(“Иман” газетасыннан)

# Гамәлдә үрнәк

Мөселман кеше, Аллаһы кушканнарны үтәү өстенә, Аның әмер-тыюларын башкаларга да җиткерергә бурычлы. Әлхәмдүлилләһ, соңгы елларда динебезнең күтәрелеше нәкъ менә дәгъват, уку-укыту күренешләренә нигезләнә. Тик әлеге җиңел булмаган хезмәт – динне тарату вакытында без кайчак бер гамәлне онытабыз. Ул да булса – чакырган изгелекне үзебез эшләү.

Коръән-Кәримдә Аллаһы Раббыбыз Бәни-Исраилгә мөрәҗәгать итеп: *«Кешеләрне тәкъвалыкка чакырып, үзегезне онытасызмы? Сез Китап (Тәүрат) укыйсыз бит! Акылыгызга килмисезмени?»* - ди. Әйе, тәкъвалыкка без дә чакырырга тырышабыз. Ләкин күп вакытта бу гамәлне үзебездән башларга тиешле булуыбыз истән чыга.

Пәйгамбәребез Мехәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләм кешеләрне Аллаһы юлына, беренче чиратта, үз гамәлләре үрнәгендә өндәгән. Әгәр сүзе һәм гамәле арасында аерма булса, галәмебездә мөселманнар саны артмас, динебез җәелмәс иде. Аллаһы илчесе салләллаһу галәйһи вә сәлләм үзенең бер хәдисендә әйткән: *«Кыямәт көнендә берәүне китерәчәкләр һәм утка ташлаячаклар. Аның эчәкләре тышка асылынып төшәчәк, һәм ул алар белән тегермән ташлары әйләндерүче ишәк кебек әйләнәчәк. Аның янына җәһәннәм әһелләре җыелачак һәм: «Сиңа нәрсә булды, фәлән? Син яхшылыкка өндәп, начарлыктан тыела алмадыңмы?!» - дип әйтәчәкләр. Ул кеше: «Әйе, мин сезне начар эштән тыйдым, ә үзем шуны эшләдем», - дип әйтер».*

Икенче бер урында Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай ди: *«Мигъраҗ кичәсендә мин иреннәре утлы кайчы белән киселгән ир кешеләрне күрдем. Мин: «Әй, Җәбраил, бу кемнәр?» - дип сорадым. Ул: «Болар - синең өммәтеңнең вәгазьчеләре. Алар кешеләрне тәкъва булырга өндиләр, Коръән укыйлар һәм үзләрен оныталар. Ул кешеләр акылга килмәсме?» - дип әйтте».*

Чыннан да, бүгенге көндә дин гыйлеменнән күпмедер өлеш алырга насыйп булган кешеләр бар. Ләкин икенче яктан карасак, мәдрәсә тәмамлап та, яулыксыз, хиҗабсыз йөргән кызлар, эти-әнисен рәнҗеткән егетләр җитәрлек. Гыйлем алу бик тә хәерле нәрсә, тик аны кулланмау, гамәл кылмау – зур яманлыктыр. Мөгаллим тарафыннан бирелгән гакыйдә, әдәп-әхлак һ.б. дәресләрне чүп урынына салып таптау - тагын да зуррак әшәкелектер.

Без еш кына Аллаһының әмерләрен үтәгәндә кешеләрнең фикеренә карыйбыз. «Намаз укысам, сүз әйтмәсләрме? Яулыктан йөрсәм, гаеп итүче булмасмы? Хәмер эчмәвем кеше көлкесе булмасмы?» кебек сораулар күпләрнең күңелләрен борчый. Әйтерсең гыйбадәтне кеше ризалыгы өчен кылалар. Әйтерсең изгелек кылып, кеше арасында хурлыкка калудан оялалар. Аллаһы Раббыбыз бу турыда: *«Теләкләреңә иярмә! Чөнки алар сине Аллаһы юлыннан адаштырачак»,* - ди.

Аллаһы Сөбханә вә Тәгалә фәкать Үзенең юлында булырга, шул юлда гамәл-гыйбадәт кылып, башкаларны да ияртергә насыйп итсә иде.

**Рөстәм хәзрәт ЯСӘВИЕВ.**
*(«Ислам нуры»)*

# “Атай малы жәл түгел”

Без садака биргәндә дә исраф итәбез. Аны тиешсез урынга бирәбез. Ул мохтаҗларга гына тиеш. Бүгенге көндә ятимнәр, гарип-горабалар, шулай ук мәчетләр мохтаҗ. Әмма бүген садака күп очракта мохтаҗларга ирешми. Аны Коръән укыган өчен, дип кенә бирәләр. Мәҗлесләрдә бер-берсенә бирешәләр дә, шуннан зур канәгатьләнү тоялар. Тиешле урынга эләкмәгәнгә, аның бәрәкәте дә юк. Ә гайбәте тарала.

Без үзебез дә уйламаган нәрсәләрдә дә исраф итәбез. Мәсәлән, суны хәзер краннардан гына агызасы. Аны көчле иттереп агызып куябыз да, иркенләп сөйләшә-сөйләшә тәһарәт алабыз. Ә мәчетнең счетчигы әйләнә, бурычы арта. Ә бит суны саграк тотсак, шәһәрнең чыгымнары да азрак булыр иде. Түләп юына торган булсак, исраф итмәс идек, әлбәттә. Исраф итү күп вакыт: «Бушка бит, минеке түгел», - дигән фикердән килә. Халыкта әйтем дә бар: «Үзем тапкан мал түгел, атайныкы жәл түгел», - дип. Бу ашауга да, киенүгә дә, барлык нәрсәләргә дә кагыла. Тәмле әйберне сатып алсак, аз-азлап берничә көн ашыйбыз, яисә кунак килгәч кенә өстәлгә куябыз.

Исраф итү ашауда, киенүдә, су куллануда гына түгел, хәтта вакыт уздыруыбызда да



булырга мөмкин. Көнгә бер сәгатькә мәчеткә киләбез. Китапларыбыз бар, укырга була, дөнья хәлләрен куеп торып, аз булса да иманыбызны куәтләсә - никадәр яхшы булыр иде. Ә без вакытны бушка уздырабыз. Ә бит вакыт - Аллаһының безгә биргән иң зур нигъмәте, хәтта Аллаһы Тәгалә «Гасыр» сүрәсендә: *«Гасырлар белән ант итәм»,* - дип әйтә.

Аллаһы Тәгалә Үзе өчен иң кадерле нәрсәсен безгә нигъмәт итеп бирә, һәм без бит шушы кадәрле нәрсә өчен хисап бирәчәкбез.

«Сез хәтта мәчеткә килгән вакытыгызны да бушка уздырдыгыз, төрле хәлләр, гайбәт сөйләштегез», - дигән сорауга ни дип җавап бирербез?

Намаз өстебезгә йөкләтелгән. Биш вакыт намазга тәүлекнең бер-ике сәгате китәдер. Ә без шуңа да вакыт тапмыйбыз. Шушы намаз вакытыннан калганы безнең ихтыярыбызда, тормышыбызга бәрәкәт бирә. Без шушы бер-ике сәгать вакытыбызны намазга кулланмаганга күрә, дә тормышыбыздан бәрәкәт китте. Эшлибез-эшлибез, хезмәт хакы алмыйбыз, йә аз алабыз, тамак туйдыру да авырая. Кемнеңдер тормыш дәрәҗәсе түбәнәя, кемнекедер күтәрелә. Әмма тормыш дәрәҗәсе арткан саен, аның кальбе фәкыйрьләнә, малын тиешле урынга тотмый, исраф итә. Аллаһы Тәгалә әйтә: *«Ий, адәм баласы, бел, кешегә хәләл ризык тамчы-тамчы килер, хәрәм ташу кебек мул килер. Һәркемнең ризыгы хәләлдән булса, дине пакь булыр».* Динебез пакь булса, тамчы-тамчы килгән хәләл ризыгыбыз мул килгән хәрәм ризыктан бәрәкәтлерәк булыр, инша Аллаһ.

Аллаһы Тәгалә һәммәләребезне дә исраф итмәүче Үзенең ихлас колларыннан кылса иде.

**Рөстәм ШӘЙХЕВӘЛИ,**
**Чаллының «Ак мәчете» имам-хатыйбы.**
*(“Татар мөселман календаре”ннан)*

# Аллаһыны ник күрмибез?

Кайберәүләр сорыйлар: «Ни өчен без Аллаһы Тәгаләне күрмибез?” Аларга ничек җавап бирергә?

Күрү - димәк, караш белән тулысынча чолгап алу. Мисал китерик. Һәр кеше организмында микроблар бар. Мәсәлән, безнең авызыбызда миллионнарча бактерияләр яши. Алар тешләребезне бозалар, черетәләр. Ә кешеләр бит моңа бәйле бернинди тавыш та ишетмиләр, микробларның анда яшәве турында уйлап та карамыйлар. Бактерияләр исә кеше кебек зур объектны кабул итә алмыйлар. Кешене күреп, үзләренең карашлары белән чолгап алыр өчен алар тулысынча мөстәкыйль булырга һәм телескоп кебек куәтле күрү сәләтенә ия булырга тиеш. Объектны караш белән тулысынча чолгап ала алмау аны күрергә комачаулык итә. Микроорганизмнар үзләренең алларында торган әйберне генә “күрәләр”.

Макродөньядан да бер мисал. Күз алдыбызга китерик: без бик куәтле телескоп аша үзебездән дүрт миллиард яктылык елы ераклыгында булган нәрсәләрне күрәбез, ди. Шул очракта да безнең Галәм һәм башка дөнья турында белгәннәребез, белмәгән нәрсәләр белән чагыштырганда, диңгездәге бер тамчы кадәр генә булачак. Үзебез күргәннәргә нигезләнеп, без яңа гипотезалар эшләп чыгарырбыз. Ләкин моның белән генә без Галәмнең ничек идарә ителүен дә, гомуми картинасын да, эчтәлеген дә күрмәячәкбез дә, белмәячәкбез дә. Чөнки, микроорганизмнар кебек үк, без дә үз карашыбыз белән шундый зур масштаблы объектны чолгап ала алмыйбыз. Кулларыбызда микроскоплар, рентген җиһазлары булса да, без барыбер макродөньяны танып бетерә алмыйбыз. Коръәндә болай язылган: *“Аллаһы Тәгаләне күзләр ихата кыла алмас, Аны күрергә бернинди күз кадир булмас, бәлки, Аллаһы Үзе күзләрне ихата кылыр, ягъни күзләрнең күрүен чолгап алыр вә Ул һәрнәрсәдән хәбәрдар”* (6:103).

Әйе, без Аны берничек тә күрә алмыйбыз. Ул Үзе бөтен нәрсәне күрә, ләкин безгә күренми.

Бу проблеманың икенче аспекты да бар. Аллаһы Нур (яктылык) белән чолганып алынган, ләкин без аны да күрмибез. Мигъраҗдан соң Пәйгамбәребез җиргә кайткач, сәхабәләреннән берсе сораган: “Ходай Тәгаләне күрдеңме?” – дип. Мөхәммәд (с.г.в.) җавап биргән: “Ул - Нур (яктылык). Ничек күрим мин Аны?” Икенче тапкыр ул әйткән: “Мин Яктылыкны күрдем”, - дигән. Ә Яктылык Аллаһы тарафыннан яралтылган. Аллаһы - Мөнәввир-ун-нур (“Галәмдәге яктылык чыганагы, Нурга яктылык бирүче”). Аллаһы Тәгалә Яктылык образын тудырган, аңа форма биргән. Яктылык - Аллаһы түгел, ә Аның иҗат җимеше, безнең белән Аллаһы Тәгалә арасында яктылык бар, ул безне Ай Арыслан йолдызлыгында чолгап алган. Ләкин бу да Яктылыкның образы гына.

Проблеманың өченче аспектын карыйк. Ибраһим Хаккый язган: “Дөньяда минем Тәңремә охшаш нәрсә дә, аңа капма-каршы нәрсә дә юк, Аның образы юк, Ул изге”.

Безнең Ходабызның капма-каршысы юк. Бу - бик әһәмиятле. Бары тик капма-каршысы булган нәрсәне генә күреп була. Мәсәлән, без яктылыкны бары тик караңгылык булганга гына күрә алабыз. Тагын бер мисал. Сез ниндидер предметларның озынлыгын чагыштырасыз: берсе - ике метр, икенчесе - өч аршын. Бу очракта да аларны чагыштыру чагыштырырлык әйбер булганга гына мөмкин.

Кешенең физик мөмкинлекләре күзлегеннән дә әлеге сорауны карап китик. Кызык, кеше үзен әйләндереп алган дөньяның нинди өлешен күрә ала икән? Безнең карашыбыз ничә предметны чолгап ала? Күз алдына китерик: бөтен Галәмдәге миллиард миллиардларча күзгә күренә торган предметлар безгә дәшә: «Зинһар өчен, карагыз, танып белегез, Аллаһыны мактагыз!” Ә без һәр миллион предметның бишесен генә күрергә сәләтле. Без билгеле бер үлчәмдәге һәм әйбәт яктыртылган предметларны гына күрәбез. Игътибар итегез: “Мин ник Аллаһыны күрмим?” - дип сораучы кеше миллионнан берничә генә предметны күрергә сәләтле, шуңа да карамастан, ул Аллаһы Тәгаләне дә күрмәкче була!

Аллаһыны бары тик даими фикер йөртү-